ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.01.2019 п.г.т. Алексеевское № 7

**“ТР Алексеевск муниципаль районы жирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмә хакында” Алексеевск муниципаль районы башлыгының 29 март, 2016 ел, 17 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 2 март, 2007 ел, 25-ФЗ санлы Федераль законга туры китерү максатында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы жирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгының 29 март, 2016 ел, 17 санлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 нче пунктчаның 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан эштән киткән көндә чыгарыла. Муниципаль хезмәткәр вафат булган (гомере киселгән) яки хәбәрсез югалган яисә законлы көченә кергән суд карары белән үлгән дип игълан ителгән очракта үлгәннең (гомере киселгәннең) икенче көнендә яки суд карары законлы көченә кергән көндә муниципаль хезмәткәр реестрыннан чыгарыла”.

1. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Алексеевск муниципаль районы Советының аппарат җитәкчесе А. Харитоновка йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А.Демидов**